**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

## Татарстан Республикасы территориясендә ауны тыю турында

2024 елда БРИКС саммитын әзерләү һәм уздыру чорында җәмәгать тәртибен саклауны һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүне көчәйтү максатларында, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларында Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 19 октябрендәге 756 номерлы Указы белән бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла торган чаралар турында» 2022 елның 19 октябрендәге 757 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм**:

1. 2024 елның 16 октябренннән 2024 елның 31 октябренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә ауның барлык төрләрен тыярга.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 22 июнь
№ 481